Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № VI-4**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 19 декабре

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указын, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын тормышка ашыру максатларында, оештыру-штат чараларына бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Көчен югалткан дип танырга:

- «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге XLI-3 номерлы карарының 1 пункты;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге XLI-3 номерлы карары белән расланган «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 25 августындагы LII-3 номерлы карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе                                                   И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2015 елның 19 декабрендәге
VI-4номерлы карары белән
расланды

**«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советында формалаштырыла торган комиссия (алга таба - комиссия) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә билгеләнә.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка муниципаль норматив хокукый актларга таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына (алга таба - җирле үзидарә органнары) ярдәм итү тора:

а) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итүдә, мәнфәгатьләр конфликтын (низагын, каршылыгын) булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәүне тәэмин итүдә (алга таба - хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр);

б) җирле үзидарә органнарында коррупцияне кисәтү чараларын гамәлгә ашыруда.

4. Комиссия «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсенең тиңдәшле органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә карата хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләрне карый.

5. Комиссия Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы карары белән төзелә. Күрсәтелгән акт белән комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана.

Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, сәркатибе һәм комиссия әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

6. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы урынбасары (комиссия рәисе), муниципаль органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (комиссия сәркатибе), муниципаль хезмәт һәм кадрлар, юридик (хокукый) бүлекчәләр, җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы билгели торган башка бүлекчәләре мәсьәләләре буенча бүлекчәдән муниципаль хезмәткәрләр;

б) эшчәнлекләре муниципаль хезмәт белән бәйле урта, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирүче фәнни оешмалар һәм мәгариф оешмалары вәкиле (вәкилләре).

7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы комиссия составына түбәндәгеләрне кертү хакында карар кабул итәргә мөмкин:

а) «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22.1 маддәсе нигезендә җирле үзидарә органы каршында төзелгән иҗтимагый совет вәкиле;

б) җирле үзидарә органында төзелгән иҗтимагый оешма вәкиле, җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эшләүче профсоюз оешмасы вәкиле.

8. Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктындагы «б» пунктчасында һәм 7 пунктында күрсәтелгән затлар, җирле үзидарә органы каршында төзелгән иҗтимагый совет белән килештереп, урта, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары һәм мәгариф оешмалары белән, җирле үзидарә органында төзелгән иҗтимагый оешма, җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эш итүче профсоюз оешмасы белән килештереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы гарызнамәсе нигезендә билгеләнгән тәртиптә комиссия составына кертелә. Килештерү гарызнамә алган көннән алып 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

9. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче комиссия әгъзалары саны комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

10. Комиссия составы комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеген булдырмау өчен төзелә.

11. Комиссия утырышларында киңәш бирү хокукы белән катнашалар:

а) Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры

җитәкчесе, һәм комиссия рәисе билгели торган муниципаль хезмәт вазыйфаларын җирле үзидарә органнарында биләүче ике муниципаль хезмәткәр, комиссия әлеге мәсьәләне карый торган муниципаль хезмәткәр биләгән вазыйфа аларныкы шикелле үк;

б) җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче башка муниципаль хезмәткәрләр; муниципаль хезмәт мәсьәләләре һәм комиссия карый торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә ала торган белгечләр; җирле үзидарәнең башка органнарының вазыйфаи затлары; дәүләт органнарының вазыйфаи затлары, кызыксынучы оешмалар вәкилләре; комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәр вәкиле - комиссия тарафыннан бу мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрнең яисә комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенечнамәсе нигезендә һәр конкрет очракта комиссия утырышы көненә кадәр кимендә өч көн кала аерым кабул ителә торган комиссия рәисе карары буенча.

12. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар үткәрү мөмкин түгел.

13. Комиссия әгъзасының турыдан-туры яисә читләтелгән шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин, ул утырыш башланганчы бу турыда хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта комиссиянең тиңдәшле әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

14. Комиссия утырышын уздыру өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан бирелә торган һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне, тикшерү материалларын үтәүне таныклый торган гражданнар тарафыннан:җирле үзидарә органы җитәкчесенә керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибен билгели торган муниципаль норматив хокукый акт нигезендә тапшыру:

муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль норматив хокукый акт нигезендә бирелә торган керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүматлар бирү турында;

муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү турында;

б) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте бүлекчәсенә яисә җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына муниципаль норматив хокукый актта билгеләнгән тәртиптә кергән:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары белән расланган вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт

вазыйфасын җирле үзидарә органында биләүче гражданның коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфасын биләүгә яисә коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга ризалык бирү турында мөрәҗәгате, бу оешма муниципаль идарә буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, муниципаль хезмәттән азат ителгән көннән алып ике ел узганчы;

муниципаль хезмәткәрнең объектив сәбәпләр буенча хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру мөмкинлеге булмау хакында гаризасы;

в) җирле үзидарә органы җитәкчесен яисә комиссиянең муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт тәртибе таләпләренең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлешен тәэмин итүгә яисә җирле үзидарә органында коррупцияне кисәтү чараларын гамәлгә ашыруга кагылышлы теләсә кайсы әгъзасын тәкъдим итү;

г) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсендәге 1 өлешендә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүматларны муниципаль хезмәткәрләргә тапшыру турында таныклый торган тикшерү материалларын җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан тапшыру;

д) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсендәге 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 маддәсе нигезендә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокукый шартнамә төзү турында коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмага хәбәр итү, әгәр әлеге оешма тарафыннан муниципаль идарәнең аерым функцияләре аның җирле үзидарә органында вазыйфасын биләгән вакытта башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә шул шартларда, әгәр күрсәтелгән гражданга элегрәк әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокук мөнәсәбәтләренә керүдән баш тарткан яки мондый гражданга коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфасын биләүгә яисә коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга ризалык бирү турындагы мәсьәлә комиссия тарафыннан каралмаган булса.

15. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

16. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан тарафыннан җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсенә тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә күрсәтелә: гражданның

фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, яшәү урыны адресы, биләгән вазыйфалары муниципаль хезмәттән азат ителгән көнгә кадәр соңгы ике ел эчендә, коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешманың исеме, урнашу урыны, аның эшчәнлеге характеры, граждан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән вакытта аның вазыйфаи (хезмәт) вазыйфаларын башкарган вазыйфаи бурычлары, коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмага карата муниципаль идарә буенча функцияләр, шартнамәнең төре (хезмәт яисә граждан-хокукый) аның гамәлдә булу срогы күздә тотыла торган, эшләр (хезмәт күрсәтүләр) шартнамәсе буенча түләү суммасы. Коррупциягә каршы көрәш һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте бүлекчәсендә "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсе таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьләрнең асылы буенча дәлилле бәяләмә әзерли торган мөрәҗәгатьне карау гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать килгән көннән соң ике эш көне эчендә мөрәҗәгать, нәтиҗә һәм башка материаллар комиссия рәисенә тапшырыла.

17. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне муниципаль хезмәттән азат итүне планлаштыручы муниципаль хезмәткәрләргә тапшырырга мөмкин һәм әлеге Нигезләмә нигезендә комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

18. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан карала, ул җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсе таләпләрен үтәү турында дәлилле бәяләмә әзерли. Хәбәрнамә, нәтиҗә һәм башка материаллар хәбәрнамә кергән көннән алып ун эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла.

19. Комиссия рәисе комиссия утырышын уздыру өчен нигез булган әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә аңа түбәндәгеләр кергәндә:

а) 3 көн эчендә комиссия утырышы датасын билгели. Мондый чакта комиссия утырышы датасы әлеге мәгълүмат кергән көннән соң җиде көннән дә соңга калмыйча билгеләнә алмый, моңа әлеге Нигезләмәнең 20 һәм 21 пунктларында каралган очраклар керми;

б) комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрнең үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең, аның вәкиле, комиссия әгъзалары һәм комиссия утырышында катнашучы башка затлар турындагы мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрне түбәндәгеләр белән таныштыруны оештыра: коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җирле үзидарә органы бүлекчәсенә яисә җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына кергән мәгълүмат һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән;

в) Комиссия утырышына әлеге Нигезләмәнең 11 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турындагы үтенечнамәне карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) һәм комиссия утырышы барышында өстәмә материаллар карау (караудан баш тарту) турында карар кабул итә.

20. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән гаризаны карау буенча комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

21. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

22. Комиссия утырышы муниципаль хезмәткәр алдында уздырыла, аңа карата хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе, яисә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан карала. Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән муниципаль хезмәткәр яки гражданинның язма үтенече булган очракта, әлеге мәсьәләне аның катнашыннан башка карау турында комиссия утырышы ул булмаганда үткәрелә. Муниципаль хезмәткәрнең (аның вәкиленең) комиссия утырышына килмәгән очракта һәм муниципаль хезмәткәрнең әлеге мәсьәләне карау турында язма үтенече булмаганда, аның катнашыннан башка бу мәсьәләне карау кичектерелә. Муниципаль хезмәткәр кабат килмәгән очракта, комиссия җитди сәбәпләрсез әлеге мәсьәләне муниципаль хезмәткәр булмаганда карау турында карар кабул итәргә мөмкин. Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан (аның вәкиле) комиссиясе утырышына килмәгән очракта, күрсәтелгән граждан яшәү урынын алмаштырган һәм комиссия утырышын уздыру датасы турында аңа мәгълүмат җиткерү буенча барлык чаралар күрелгән очракта, комиссия әлеге мәсьәләне күрсәтелгән граждан булмаганда карау турында карар кабул итәргә мөмкин.

23. Комиссия утырышында җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрнең яисә гражданның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка чыгарылган сорауларның асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

24. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны фаш итәргә хокуксыз.

25. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында

мәгълүматлар бирү тәртибен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүләрен билгели торган муниципаль норматив хокукый акт нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә тапшырылган мәгълүматлар дөрес һәм тулы булып тора дип билгеләргә;

б) әлеге пунктның «а» пунктчасында аталган муниципаль норматив хокукый акт нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә тапшырылган мәгълүматлар дөрес һәм (яисә) тулы түгел дип билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәрләргә җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга киңәш итә.

26. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәвен билгеләргә;

б) муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәвен билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне бозуның ярамаганлыгын күрсәтергә яисә муниципаль хезмәткәргә конкрет җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

27. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә яисә коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга ризалык бирергә, әгәр бу оешма муниципаль идарә буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә;

б) коммерцияле яки коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эшне коммерцияле яки коммерциячел булмаган оешмада башкарудан баш тартырга, әгәр бу оешманың муниципаль идарә буенча аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) вазифаларына кергән булса һәм үз вазифасыннан баш тартуны дәлилләсә.

28. Әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәргә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны тапшырмау сәбәбе объектив һәм нигезле дип танырга;

б) муниципаль хезмәткәргә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны тапшырмау сәбәбе нигезле түгел дип танырга. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыру чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) муниципаль хезмәткәргә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны тапшырмау сәбәбе объектив түгел дип танырга һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан читләшү ысулы булып тора. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга киңәш итә.

29. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" Федераль законның 3 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар дөрес һәм тулы булып тора;

б) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законның 3 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырылган мәгълүматларны дөрес һәм (яисә) тулы түгел дип танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә конкрет җаваплылык чарасын кулланырга һәм (яки) чыгымнарны тикшереп тору нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яисә) бүтән дәүләт органнарына аларның компетенциясе нигезендә җибәрергә тәкъдим итә.

30. Әлеге нигезләмәнең 14 пунктының «а», «б», «г» һәм «д» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча комиссия әлеге Нигезләмәнең 25-29 һәм 31 пунктларында каралганнан башкача карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм сәбәпләре комиссия утырышы беркетмәсендә чагылырга тиеш.

31. Әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада аның вазыйфасын биләүгә яисә коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга ризалык бирергә, әгәр муниципаль идарә буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә;

б) аларга хезмәт шартнамәсе шартларында коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазыйфалар биләү һәм (яисә) коммерциячел яки коммерциячел булмаган эшләрне (хезмәтләр күрсәтүне) үтәү «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәләре таләпләрен боза дип билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә күрсәтелгән хәлләр турында прокуратура органнарына һәм оешмага хәбәр итәргә тәкъдим итә.

32. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «в» пунктчасында каралган мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия тиңдәшле карар кабул итә.

33. Комиссия карарларын үтәү өчен җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлары проектлары, җирле үзидарә органы җитәкчесенең билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органы җитәкчесе каравына тапшырыла торган карарлары яисә йөкләмәләре әзерләнергә мөмкин.

34. Комиссиянең әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлары комиссия утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә (әгәр комиссия башка карар кабул итмәсә).

35. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга комиссия утырышында катнашкан әгъзалар имза сала. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карардан тыш, җирле үзидарә органы җитәкчесе өчен рекомендация характерында йөриләр. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри характерда була.

36. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) комиссия утырышы датасы, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме;

б) комиссия утырышында карала торган һәр сорауның тәгъбирләнеше, аңа карата хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган муниципаль хезмәткәрнең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп;

в) муниципаль хезмәткәргә карата дәгъва белдерелә торган, алар нигезләнә торган материаллар;

г) муниципаль хезмәткәрнең һәм башка затларның белдерелә торган дәгъваларның асылы буенча аңлатмаларның эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме һәм аларның чыгышларын кыскача бәян итү;

е) комиссия утырышын уздыру өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы, җирле үзидарә органына мәгълүмат керү датасы;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) аны кабул итү карары һәм нигезләмәсе.

37. Комиссия карары белән килешмәүче әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәп бирелергә һәм аның белән муниципаль хезмәткәр танышырга тиеш.

38. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш көненнән алып 3 көн эчендә җирле үзидарә органы җитәкчесенә, тулысынча яисә аннан өземтә рәвешендә - муниципаль хезмәткәргә, шулай ук комиссия карары буенча башка кызыксынучы затларга җибәрелә.

Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителгән карар турында комиссия гражданга бер эш көне дәвамында язма хәбәрнамә җибәрә һәм аңа өч эш көне эчендә телдән хәбәр итә.

39. Җирле үзидарә органы җитәкчесе комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм үз компетенциясе чикләрендә муниципаль хезмәткәргә куллану турында карар кабул иткәндә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен һәм кабул ителгән карарны карау турында җирле үзидарә органы җитәкчесе язма рәвештә комиссиягә комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән соң бер ай эчендә хәбәр итә. Җирле үзидарә органы җитәкчесенең карары комиссиянең якындагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышмыйча гына игътибарга алына.

40. Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар гамәл билгеләре билгеләнгән очракта, бу хакта мәгълүмат муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне хәл итү өчен җирле үзидарә органы җитәкчесенә тапшырыла.

41. Комиссия административ хокук бозу билгеләрен яисә җинаять составын үз эченә алган гамәл кылу факты (гамәл кылмау факты) ачыкланган очракта, комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлне (гамәл кылмау) кылу турында мәгълүматны һәм мондый фактны хокук куллану органнарына 3 көн эчендә, ә кирәк булганда - кичекмәстән җиткерә торган мәгълүмат тапшырырга тиеш.

42. Комиссия утырышы беркетмәсе күчермәсе яки аннан өземтә аңа карата хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр каралган муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә тыгыла.

43. Комиссия сәркатибе имзасы һәм җирле үзидарә органы мөһере белән расланган комиссия карарыннан өземтә аңа карата әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданга тапшырыла, тиңдәшле комиссия утырышын уздыру көненнән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча имза куйдырып яки заказлы хат белән җибәрелә.

44. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирү, комиссия әгъзаларын комиссия утырышында фикер алышу өчен тәкъдим ителә торган материаллар белән таныштыру коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органының кадрлар хезмәте бүлекчәсе яки җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.